МИНИСТЕРСТВО ПО ДЕЛАМ ГРАЖДАНСКОЙ ОБОРОНЫ И ЧРЕЗВЫЧАЙНЫМ СИТУАЦИЯМ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ГРАЖДАННАР ОБОРОНАСЫ ЭШЛӘРЕ ҺӘМ ГАДӘТТӘН ТЫШ ХӘЛЛӘР МИНИСТРЛЫГЫ

**ПРИКАЗ** г. Казань **БОЕРЫК**

04.07.2024 № 169

**Татарстан Республикасы Гражданнар оборонасы эшләре һәм гадәттән тыш хәлләр Министрлыгының 07.09.2023 № 228 боерыгы белән расланган Татарстан Республикасы Дәүләт граждан хезмәткәрләренең хезмәт тәртибенә таләпләрне үтәү һәм мәнфәгатьләр конфликтын җайга салу буенча Татарстан Республикасы Гражданнар оборонасы эшләре һәм гадәттән тыш хәлләр Министрлыгының Комиссиясе турында Нигезләмәгә үзгәрешләр кертү турында**

Россия Федерациясе Президентының «Дәүләт граждан хезмәткәрләренең хезмәт тәртибенә таләпләрне үтәү һәм мәнфәгатьләр конфликтын җайга салу комиссияләре турында» 2010 ел 1 нче июль № 821 Указына үзгәрешләр кертүгә бәйле рәвештә б о е р ы к  б и р ә м:

1. Татарстан Республикасы Гражданнар оборонасы эшләре һәм гадәттән тыш хәлләр Министрлыгының 07.09.2023 № 228 боерыгы белән расланган Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәткәрләренең хезмәт тәртибенә таләпләрне үтәү һәм мәнфәгатьләр конфликтын җайга салу буенча Татарстан Республикасы Гражданнар оборонасы эшләре һәм гадәттән тыш хәлләр Министрлыгының Комиссиясе турында Нигезләмәгә алдагы үзгәрешләрне кертергә:

3 нче пунктның «а» пунктчасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«а) Татарстан Республикасы Гадәттән тыш хәлләр Министрлыгында Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәткәрләренең (алда - дәүләт хезмәткәрләре) коррупциягә каршы эш (алда - хезмәт тәртибенә һәм (яисә) мәнфәгатьләр конфликтын җайга салу турындагы таләпләр) максатларында «Коррупциягә каршы тору турында» 2008 ел 25 нче декабрь № 273-ФЗ

Федераль законда, башка федераль законнарда билгеләнгән чикләүләрне һәм тыюларны, мәнфәгатьләр конфликтын булдырмау яисә җайга салу турындагы таләпләрне, бурычларны үтәвен тәэмин итүдә;»;

15 нче пунктка түбәндәге эчтәлекле «е» пунктчасы өстәргә:

«е) хезмәт тәртибенә салынган таләпләрне һәм (яисә) мәнфәгатьләр конфликтын җайга салу турындагы таләпләрне үтәүгә комачаулый торган аңа бәйле булмаган хәлләр барлыкка килү турында дәүләт хезмәткәренә хәбәр итү.»;

20 нче пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«20. Әлеге Нигезләмәнең 15 пунктындагы «б» пунктчасының бишенче абзацында һәм «е» пунктчасында күрсәтелгән хәбәрнамәләр Татарстан Республикасы ГТХМ кадрлар хезмәтенең белдерүләрне карау нәтиҗәләре буенча дәлилләнгән бәяләмәләр әзерләүче, коррупциячел һәм башка хокук бозуларны профилактикалау эше өчен җаваплы вазыйфаи заты тарафыннан карала.»;

21 нче пунктта:

беренче абзацта «15 нче пунктының «д» пунктчасында» сүзләрен «15 нче пунктының «д» һәм «е» пунктчаларында» сүзләренә алыштырырга;

«а» пунктчасында «15 нче пунктының «д» пунктчасында» сүзләрен «15 нче пунктының «д» һәм «е» пунктчаларында» сүзләренә алыштырырга»;

«в» пунктчасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«в) әлеге Нигезләмәнең 15 пунктындагы «б» пунктчасының икенче һәм бишенче абзацларында, «д» һәм «е» пунктчаларында күрсәтелгән мөрәҗәгатьләрне һәм хәбәрнамәләрне алдан карау нәтиҗәләре буенча дәлилләнгән нәтиҗә, шулай ук әлеге Нигезләмәнең 30, 34, 34.1, 36 пунктлары яисә башка карар нигезендә карарларның берсен кабул итү өчен тәкъдимнәр.»;

24 нче пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«24. Әлеге Нигезләмәнең 15 нче пунктындагы «д» һәм «е» пунктчаларында күрсәтелгән хәбәрнамәләр, кагыйдә буларак, Комиссиянең чираттагы (план) утырышында карала.»;

25 нче пунктта:

беренче абзацта «15 нче пунктының «б» пунктчасы» сүзләрен «15 нче пунктының «б» һәм «е» пунктчалары» сүзләренә алыштырырга»;

«а» пунктчасында «15 нче пунктының «б» пунктчасы» сүзләрен «15 нче пунктының «б» һәм «е» пунктчалары» сүзләренә алыштырырга»;

түбәндәге эчтәлекле 34.1 пункт өстәргә:

«34.1. Әлеге Нигезләмәнең 15 пунктындагы «е» пунктчасында күрсәтелгән мәсьәләне карау йомгаклары буенча Комиссия түбәндәге карарларның берсен кабул итә:

а) дәүләт хезмәткәренә бәйле булмаган хәлләр килеп чыгу һәм аның хезмәт тәртибенә карата таләпләрне һәм (яисә) мәнфәгатьләр конфликтын җайга салу турындагы таләпләрне үтәү мөмкин түгеллеге арасында сәбәп-нәтиҗә бәйләнеше булуын таныրга;

б) дәүләт хезмәткәренә бәйле булмаган хәлләр килеп чыгу һәм аның хезмәт тәртибенә карата таләпләрне һәм (яисә) мәнфәгатьләр конфликтын җайга салу турындагы таләпләрне үтәү мөмкин түгеллеге арасында сәбәп-

нәтиҗә бәйләнеше булмавын танырга.»;

35 нче пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«35. Әлеге Нигезләмәнең 15 нче пунктындагы «а», «б», «г», «д» һәм «е» пунктчаларында күрсәтелгән мәсьәләләрне карау йомгаклары буенча һәм моңа нигезләр булганда, Комиссия әлеге Нигезләмәнең 28-34.1 һәм 36 пунктларында каралганнан бүтән карар кабул итәргә мөмкин. Мондый карар кабул итү нигезләре һәм мотивлары комиссия утырышы беркетмәсендә чагылдырылырга тиеш.».

2. Әлеге боерыкны Татарстан Республикасы Гадәттән тыш хәлләр Министрлыгының министр урынбасарларына, структур бүлекчәләре җитәкчеләренә һәм хезмәткәрләренә җиткерергә.

Министр вазыйфаларын
вакытлыча башкаручы Н.В. Суржко